Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

15 ноябрь 2018 ел №255

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 25 апрелендәге №375 «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында җитәкче вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакант кадрлар резервы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы №25-ФЗ «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәтләр турында» Федераль Законга, Татарстан Республикасы Законының 2013 елның 25 июнендәге №50-ТРЗ «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтләр турында»гы Кодексына, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәтләр турындагы Нигезләмәсенә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында җирле үзидарә органнарында җитәкче вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакант кадрлар резервы турында килешүләр нигезендә төзелгән 2018 елның 7 маендагы №178 хокукый мониторингка нигезләнеп,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 25 апрелендәге №375 «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында җитәкче вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакант кадрлар резервы турында» (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль район Советының 2015 елның 23 сентябрендәге №7, 2017 елның 31 маендагы №185, 2017 елның 25 сентябрендәге №203 карарлары белән керткән үзгәрешләрне исәпкә алып)түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның II нче «Резерв кадрлар туплау (формалаштыру)» бүлегенең 17 пунктын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

- муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкарырга теләк белдергән гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрнең информацион «Интернет» челтәре сайтларында урнаштырылган белешмәләре яки әлеге сайтларның адреслары турында мәгълүмат, аларны идентификацияләү мөмкинлеге:

1.2. карарның 3 нче кушымтасына:

1.2.1. Белоногованы О.Т., Шәйхулованы Ф.Х. комиссия составыннан чыгарырга.

1.2.2. комиссия составына:

- Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар һәм бүләкләр бүлеге житәкчесе вазыйфаларын башкаручы, комиссия сәркатибе Алееваны А.Р. кертергә;

1.2.3. яңа редакциядә комиссия әгъзаларының вазыйфаларын күрсәтергә:

- Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый идарә начальнигы, комиссия әгъзасы Ханнанова Ә.Б.

2. Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»на (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольга алуны район Советының закон, хокук саклау, депутат этикасы һәм жирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин